**Д.Х.Хөснетдинов**

**Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан**

# ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНДА РУХИ МӘДӘНИЯТНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ (“ХӘСРӘТ” КОНЦЕПТЫ МИСАЛЫНДА)

(Тикшеренүләр *11-14-1602а/В* (РГНФ) номерлы грант кысаларында башкарылды)

Халык авыз иҗаты дип – халык тарафыннан телдән иҗат ителеп, халык хәтерендә сакланып килгән чәчмә яки тезмә әсәрләр җыелмасын атыйлар. Соңгы елларда халык авыз иҗатын атау өчен фольклор, халыкның поэтик иҗаты, халыкның сүз сәнгате атамалары да кулланылышта йөри.

Фольклор, сүз сәнгатенең бер канаты буларак, әдәби иҗат кануннарыннан аерылып торган үз закончалыклары, тирәлекне үзгә танып белү юллары белән дөньяга килә. Аның иң беренче үзенчәлеге төсендә шәхсилек (индивидуальлек) сыйфатын аерып куярга мөмкин. Бу сыйфат иҗатчының “кабатланмас әсәр” иҗат ителүе белән бәйләнештә карала, әсәрләрнең стилендә дә, образлылыкта да чагылыш таба. Икенчедән, фольклор әсәрләре моңа кадәр булган тәҗрибәне файдалану нәтиҗәсе буларак дөньяга килә. Аларда, яңаны тудыруга караганда, моңа кадәр тупланганны яңарту, шуны персонажлар, геройлар тарафыннан җиткерү сыйфатлары алга чыга. Өченчедән, фольклор әсәрләренең авторы билгеле булмый, күбесенчә, беренче башлап, аерым талантлар тарафыннан телдән иҗат ителә, бик күбесе язмача теркәлми кала, телдән-телгә күчеп бару юлында шактый гына үзгәрешләргә дә дучар була. Дүртенчедән, халык авыз иҗаты синкретик иҗат төре булып тора. Татар фольклорына бер үк әсәр чикләрендә берничә жанрга туры килгән сыйфатларны берләштерү хас. Бишенчедән, фольклор әсәрләренә поэтик үзгәлек хас. Нигездә, аларның күбесе тыңлаучы өчен иҗат ителә, шуңа мөнәсәбәттә биредә тыңлаучыга мөрәҗәгать алга чыга. Моннан тыш халык массасына йөз

тоткан фольклор әсәрләре халыкның кызыксынуын, зәвыгын һ.б. искә алып, халык тормышы белән тыгыз бәйләнештә дөньяга килә.

Төп эчтәлеге, сюжет-композициясе, образлар системасы һәм иҗат ителү үзенчәлекләре ягыннан халык авыз иҗаты әсәрләре арасында эпик, лирик характердагылары бар. Фольклорда эпик әсәрләр рәтендә борынгы миф һәм мифологик хикәят, әкият, чәчмә дастан, риваять һәм легенда, мәзәк, мәкаль-әйтем, табышмак кебек жанрлар карала. Лирик әсәрләр исә җыр, такмак һәм такмаза, мөнәҗәт кебек жанрлар билгеләнә [Әдәбият белеме, 2007: 207-211]. Моннан тыш халык авыз иҗатында эпик һәм лирик төргә хас үзенчәлекләрне бергә туплаган лиро-эпик әсәрләр дә урын ала: бәет, шигъри дастан, тарихи җыр жанрлары шуңа дәлил булып тора.

Татар халык иҗатында туган җирнең, туган илнең кадере, аны башка бер нәрсә белән дә тиңләп булмавы һәм туган җиргә карата булган ярату-кадернең никадәр зур булуы, күңелләрнең никадәр түрендә урнашуы чит илдә, чит төбәктә тагын да ныграк сизелүе хакында сүз бара. Дөнья буенча чәчелеп урнашкан татар халкының милли аңы өчен бу концепт аеруча мөһим.

*Туган илдән аерылганга*

*Кайгы-хәсрәт башымда* [Кыска җырлар, 1976: 120].

*Сезнең белән бер авылда булсам үзем,*

*Хәсрәтемнең бик күбесе бетәр иде* [Бәетләр, мөнәҗәтләр, 2000: 132].

Бигрәк тә чит җирләрдә үлеп калу, туган илдән еракта җирләнү татарлар өчен бик күңелсез күренеш булып тора.

*Еракка китеп вафат булгач,*

*Бигрәк авыр хәсрәт* [Бәетләр, мөнәҗәтләр, 2000: 55].

“Хәсрәт” концепты татар халкының кыска җырларында күбрәк сөйгән ярны сагыну мәгънәсендә килә. Аралар ерак, очрашып булмый, шуңа да бер-берләрен сөючеләр хәсрәтләнәләр:

*Бер хәсрәтем бетәр иде*

*Сине күреп сөйләшсәм* [Кыска җырлар, 1976: 295].

Хәтта кайбер кыска җырларда гашыйк булмаска, гыйшык тотмаска өндәүче юлларны да очратырга мөмкин. Бу очракта хәсрәт белән мәхәббәт арасында параллель уздырыла: бу татар тарихында бер-берләрен яратучы кешеләрнең аерылырга, бергә булмаска дучар булулары белән бәйле.

*Тотма гыйшык, тотма хәсрәт:*

*Хәсрәт йөзне саргайта* [Кыска җырлар, 1976: 217].

Шулай ук сөйгән кешең булмау, ялгызлыктан тилмерү мәгънәләрендә дә килә ала. Чөнки үз парын тапмаган кеше канатсыз кош кебек, иртә кипкән чәчәк кебек.

*Үзем дә шул кош кебек булдым,*

*баскан ботагым каерылды,*

*Ялгызлык хәсрәте белән*

*йөземә сары коелды* [Бәетләр, мөнәҗәтләр, 2000: 144].

Гадәттә, татарлар сагыш хисен төс белән күрсәткәндә сары төсне сайлыйлар (мәсәлән, сары сагышка бату (фраз.)), ә биредә без хәсрәтнең дә йөзне саргайтучы икәнен күрәбез.

Сугыш афәте һәрвакытта да кешелеккә зур югалтулар, кайгы-борчулар, бәла-казалар алып килә, ә татар тарихында мондый афәтләр еш кабатланган:

*Бигрәк авыр икән сугыш хәле,*

*Эчкә хәсрәт уты кабынган* [Бәетләр, мөнәҗәтләр, 2000: 95].

Үлем, якын кешеңне югалту иң зур хәсрәтләрнең берсе булып тора, бигрәк үзеңә яшәү иңдергән эти-әни үлеме.

*Әнкәем дөнья куйды, башыма хәсрәт кунды* [Бәетләр, мөнәҗәтләр, 2000: 61].

Татар халык иҗаты үрнәкләрен тикшергәндә *“бала хәсрәте”* сүзтезмәсен еш очратырга була. Чөнки бала ата-ана өчен иң кадерле, иң

газиз кеше. “Ана күңеле – балада, бала күңеле – далада”, ди халык мәкале. Әти-әни һәрвакыт баласы өчен борчылып, ут йотып йөри.

*Күзләре сукырайган, баланың хәсрәтеннән, күрмәс булган* [Дастаннар, 2001: 92].

*Баланың хәсрәте үзе белән бергә үсә* [Мәкаль һәм әйтемнәр, 1987: 395].

Хәсрәтнең төрлесе була: бала хәсрәте дә, мал хәсрәте дә, яр хәсрәте дә. Яр хәсрәте мал хәсрәтеннән авыррак булып күзаллана, чөнки мал, байлык ул бүген бар, иртәгә юк, үзгәрүчән төшенчә, ә чын мәхәббәт мәңгелек.

*Мал хәсрәте хәсрәт түгел,*

*Яр хәсрәте хәстә итә* [Кыска җырлар, 1976: 58].

Юкка да борчылып, элек булган хәсрәтләр өчен юкка күз яше түгеп йөрүчеләр дә юк түгел. Татар халык мәкальләрендә әлеге кешеләр тәнкыйть ителәләр:

*Иске хәсрәт өчен яңадан күз яше агызу акыллылык түгел* [Мәкаль һәм әйтемнәр, 1987: 420].

Хәсрәтләр, борчулар күп булу тормыш ямен татып яшәүгә комачаулый, дөньяны караңгылый:

*Хәсрәтләрең, уең күп булса,*

*Якты дөнья була караңгы* [Кыска җырлар, 1976: 38].

“Хәсрәт” концепты бәла-каза мәгънәсендә килеп, түзеп булмый торган, хәтта “дивана”га әйләндерергә, юләрләндерергә сәләтле көч буларак та тасвирлана.

*Йөрәктә ут тоташкан яна-яна;*

*Бу хәсрәтләр кыйла мине дивана* [Бәетләр, мөнәҗәтләр, 2000: 139].

*Эчем тулы хәсерәткә*

*Илла чыдый күкерәк* [Кыска җырлар, 1976: 45].

Югарыда күренгәнчә, әлеге хәсрәтләргә җансыз предмет булган агач та түзә алмас иде.

“Хәсрәт” концепты дини аспектта да очрый, пәйгамбәрләр дә хәсрәт чиккән, хәсрәт күргән. Һәм әлеге хәсрәтләргә түзәргә, сабыр итәргә кирәк.

*Өмет өчен күп көйгән, күп хәсрәтләр җыйган,*

*Бик күп михнәтләр чиккән, ул – Мостафа Мөхәммәд* [Бәетләр, мөнәҗәтләр, 2000: 119].

*Бу хәсрәттән үлми калмам,*

*Ходай сабыр бирмәсә* [Кыска җырлар, 1976: 38].

“Хәсрәт” лексемасы теләкләр әйткән вакытта, хәсрәтсез тормыш теләгәндә еш кулланыла һәм бәхетле, рәхәт яшәүнең капма-каршы мәгънәсен белдереп килә:

*Бәгырькәем, рәхәт яшә*

*Кайгы-хәсрәт күрмичә* [Кыска җырлар, 1976: 288].

Татар халык иҗатында “Хәсрәт” концептын өйрәнгәндә, тарихта билгеле булган татар кызларының аяныч язмышы турындагы мәгълүматларны да күрә алабыз. Кыз бала тугач, имәнә җир бирмәү, үсә төшкәч, яратмаган кешеләренә көчләп кияүгә бирү, “курчак” булып яшәргә дучар булулары – барысы да гасырлар буена кыз бала җилкәсенә төшкән.

*Төрле хәсрәт күрмәс идем*

*Мин бәхетле кыз булсам* [Кыска җырлар, 1976: 130].

Тик ир балаларга да язмыш гел елмаеп тормый. Хәрби хезмәткә бару, сугышка китү куркынычы аларны да сагалап тора.

*Бу хәсрәтне күрми калмас*

*Ир баласы бар кеше* [Кыска җырлар, 1976: 100].

Хәсрәт шулай ук кеше ихтыярыннан бәйсез рәвештә килүче һәм аны авыр кичерешләргә салучы актив, хәрәкәтчән нәрсә буларак та күзалланырга мөмкин икән.

*Ай, бик авыр дөнья хәсрәтләре,*

*Каннар савып бетте йөрәккә* [Кыска җырлар, 1976: 45].

Тикшерелгән мисалларда күренгәнчә, хәсрәт сүзе белән түбәндәге сүзтезмәләр дә кулланылган: хәсрәт чылбыры, хәсрәт күле, хәсрәт суы, хәсрәтле җыр.

*Кая барсам да чорналам*

*Хәсрәт чылбырларына* [Кыска җырлар, 1976: 57].

*Бер тибрәнсәм чыгарым күк*

*Хәсерәт күлләреннән* [Кыска җырлар, 1976: 67].

*Ике туганның хәсрәтле җырын халык бик тиз отып алган, ди* [Риваятьләр һәм легендалар, 2001: 93].

Хәсрәт хисенең кыенлыгын янар таулар белән, зурлыгын Урал таулары белән, шомлылыгын караңгы төн белән чагыштыралар:

*Хәсрәтем охшый янар тауларга* [Бәетләр, мөнәҗәтләр, 2000: 103].

*Караңгы төннән караңгы,*

*Хәсерәтле көннәрем* [Кыска җырлар, 1976: 58].

Төрле авырлыклар, бәла-казалар кешеләрнең сәламәтлегенә зур зыян китерүен күрәбез.

*Күп хәсрәт тоткан егетләр*

*Авырмаса да сау булмас* [Кыска җырлар, 1976: 68].

“Хәсрәт” лексемасы юрауларда да очрарга мөмкин, чөнки татар халкында күз тарту, йөрәк ашкыну сөенечкә яисә көенечкә юрала.

*Уңлы-суллы күзем тарта,*

*Көн дә хәсрәтем арта* [Кыска җырлар, 1976: 70].

Әлеге сүзнең фразеологик берәмлекләр компоненты буларак кулланылуы да гадәти күренеш.

Без тикшергән татар халык иҗаты мисалларында түбәндәге фразеологизмнар очрады: *хәсрәт уты* – хәсрәт, газап, аһ-ваһ ялкыны мәгънәсендә:

*Эчкә хәсрәт уты кабынган* [Бәетләр, мөнәҗәтләр, 2000: 95]

*Эчем тулы хәсрәт уты,* -

*Сүнми дә, сүрелми дә* [Кыска җырлар, 1976: 61].

Түбәндәге мисалда хәсрәт шулай ук җисми, субстанциональ әйбер булып аңлашыла:

*Бар хәсрәтем тараладыр*

*Иркәм килеп кочканда* [Кыска җырлар, 1976: 45].

Самими дөнья күренешендә әлеге концепт физик зыян салучы, йөрәкне кимерүче, йөзне саргайтучы, хәтта үтерүче ниндидер тере зат буларак күзалланырга мөмкин:

*Кайгы-хәсрәтләр белән*

*Ярылыр каберләрем* [Кыска җырлар, 1976: 66].

*Тутык тимерне ашый, хәсрәт йөрәкне ашый* [Мәкаль һәм әйтемнәр, 1987: 428].

*Авыр кайгы, каты хәсрәт*

*Ашый йөрәк итемне* [Кыска җырлар, 1976: 59].

*Ак йөзләрем сары булды,*

*Төрле хәсрәт-уй белән* [Кыска җырлар, 1976: 61].

*Ак йөзләрем саргайды инде*

*Бу кайгы-хәсерәткә* [Кыска җырлар, 1976: 66].

*Бу хәсрәтдин вафат булсам,*

*Хәлемне һич кеше белмәс* [Бәетләр, мөнәҗәтләр, 2000: 125].

Хәсрәт лексемасы кайгы сүзе белән сөйләмдә еш кулланылучы кайгы-хәсрәт дигән парлы сүзне төзи:

*Саргайды нурлы йөзләрем*

*Кайгы-хәсерәт белән* [Кыска җырлар, 1976: 68].

Шулай ук “хәсрәт” концепты уй сүзе белән еш кына янәшә очрый. Ул гына да түгел, уй сүзе белән парлы сүз дә төзи:

*Нурлы гына йөзләр ник саргаймас*

*Төрле хәсрәт, төрле уй белән* [Кыска җырлар, 1976: 41].

*Эчкенәе тулы уй-хәсерәт –*

*Сер белгертмәс егет уявы* [Кыска җырлар, 1976: 75].

*Уй-хәсрәтләрем дә юк кебек,*

*Йөрәкләрем яна ут кебек* [Кыска җырлар, 1976: 39].

Карап үтелгән мисаллардан күренгәнчә, хәсрәт кеше күңелен тутыручы ниндидер сыеклык буларак та күзаллана, ул кайный һәм ташып чыга. Хәсрәт шулай ук ут белән ассоциацияләнә, ул янарга һәм көяргә мөмкин.

Әдәбият

1. Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2007. – 231 б.

2.Заманалар узган – дастан туган: Дастаннар. – Казан: Мәгариф, 2001. – 175 б.

3.Сүз эчендә хикмәт бар: Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 1999. – 287 б.

4. Тарих мең дә сигез йөз дә: Бәетләр, мөнәҗәтләр. – Казан: Мәгариф, 2000. – 159 б.

5. Татар халык иҗаты: Кыска җырлар (дүртюллыклар). – Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. – 390 б.

6. Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1987. – 590 б.